

ISSN 0868-4545

Салават күпере

01!

„Кызыл Әтәч" кукәй саламы?



«Кызыл Әтәч»нең нәрсә икәнен, шәт, беләсездер инде. Гадәттә, янгынны шулай дип атыйлар. Мәсәлән, ниндидер явыз бәндә кемнеңдер йортына «Кызыл Әтәч» җибәргән, ягъни ут төрткән дип әйтәләр.

Өй яки бүтән нәрсә янганны күргәнегез бардыр инде. Әгәр булмаса — ул иң бәхетле кеше! Күрергә дә язмасын!!!

Гадәттә, без утны, янгынны шырпыдан гына чыга дип уйларга өйрәнгән. Юк шул! Сүндермичә калган тәмәке төпчегеннән дә, үтүк, телевизор яки башка нәрсәләр аркасында да булырга бик мөмкин ул!

Янгын чыгуга өлкәннәр генә гаепleme соң? Һич юк! Балаларның да монда өлеше зур икән. Менә игътибар итегез: узган 1995 нче елда балалар гаебе аркасында Татарстанда 285 янгын (пожар) булган. Коточкыч саннар бит, әйеме! Быел, әле август ае гына, балалар гаебе белән 240 янгын чыккан. Кадерле укучым, ел тәмамланмаган да бит әле! Һәр янгын кешеләргә күпме бәла-каза китерә, ничаклы күз яшьләре түгелә бит!.. Әйдәгез, шул хакта уйлашыйк әле.

Зур завод-фабрикаларны, яшел, кара урманнарны, матур өйләребезне, сак булмасак, «Кызыл Әтәч» дигән янгын мизгел эчендә юкка чыгара ала! Беребез дә онытмыйк әле шуны!.. «Кызыл Әтәч» ялгыш «күкәй салмасын», ягъни үрчемәсен, булмасын иде!

Исхак Габделбарый углы Низаметдинов, Татарстан эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы Дәүләт Идарәсенең җитәкчесе, полковник.

ЯНГЫН СҮНДЕРҮЧЕЛӘР ЭМБЛЕМАСЫ



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

© «Салават күпере», 1996 ел

«Мин аны яратам, мин аннан куркам».

ДУС ТА, ДОШМАН ДА

Ут безгә дус та, дошман да. Ут саклана белсәң генә дус ул. Сансыз булсаң, мизгел эчендә дошманга әйләнә. Юкка гына: «Бурдан кала, уттан калмый»,— дип әйтмәгәннәр.

Без болыннарда, урманнарда учак ягабыз. Саксыз кыланабыз, шул учактан таралган ут ботен урманны яндырып бетерергә момкин!

Сүндерергә онытылган газ, үтүкләр, балаларның шырпы белән уйнаулары матур өйләрне колгә әйләндерә!

Альбина ЧУЛАКОВА,
4 нче сыйныф.

БӘЛА АЯК АСТЫНДА ЙӨРИ

Бер шырпыдан яки утлы күмердән килеп чыккан бәла... Аннан соң кайгы-хәсрәт, күз яшьләре, яралы йорәк!.. Бер вакыйганы язмыйча түзә алмыйм.

Ул конне Ләйлә әнисе белән Казанга барып кайта. Өйгә кайткач, әнисе мичкә ягып җибәрә. Кон кичкә авышкан була инде. Әнисе авылның икенче башында яшәүче дәү әнисенә күчтәнәч илтә китә. Ләйлә ишекне эчтән бикләп кала. Түр бүлмәдәге мичтә ялкынланып каен утыннары яна. Ләйлә, кызыксынып, идәндә яткан кәгазь тартманы мичкә ташлый. Ут кочәеп китә. Ялкынның телләре матур: алсу, кызыл. Ләйлә, мавыгып китеп, мичкә тагын бер кәгазь тартма ата. Тик яна башлаган тартма кире идәнгә тошә. Әүвәл идәндәге паласка ут каба. Аннары ялкын телләре тәрәзә пәрдәләренә, диван җәймәсенә үрелә. Кызчык ни эшләргә дә белмичә ой буенча елап тик йогереп йори. Ут ялкыны тиз арада ботен ойне чолгап ала. Кызчык, тотенгә буылып, идәнгә егыла. Янгын күреп ярдәмгә килгән кешеләр ишекне ватып ачканда, Ләйләнең нәни йорәге тибүдән туктаган була инде... Идән уртасында курчагын кочаклап яткан Ләйләнең гәүдәсен күрше егете Рәшит алып чыга...

Шушы хәлдән соң Ләйләнең әнисе Зәкия апаны хастаханәгә озаттылар. Бик озак ятты ул анда.

Йа, хода! Әгәр үткәнне кире кайтара алса, Зәкия апа беркайчан да сабыен ойдә ялгыз калдырмас иде!

Ә кечкенә Ләйлә, исән булса, мәңге ут белән уйнамас иде!..

Кем гаепле соң? Мичтәге учакмы? Әнисеме? Кечкенә Ләйлә үзе гаепләме?

Зәкия апаның: «Әти-әниләр, балаларыгызны саклагыз! Балалар! Зинһар, ут белән уйный күрмәгез!»—дип ботен доньяга кычкырасы килә...

Люция ЗЫЯТДИНОВА,
Лаеш районы Имән Кискә урта мәктәбе, 4 нче сыйныф.

ҮЗ КҮЗЛӘРЕМ БЕЛӘН КҮРДЕМ!

Ут белән бик сак булырга кирәк! Урмандагы янгын бигрәк тә куркыныч. Аны туктатуы да кыен. Кешеләрнең еллар буе үстергән яшел дуслары бер шырпы ярдәмендә һәлак булачак.

Мин үз күзләрем белән сарайлар янганын күрдем. Миңа бик куркыныч булды. Янгын сүндерүчеләр белән авыл халкы бу утны сүндерделәр, әлбәттә. Әмма күпме зыян килде!

Чулпан ГАРИПОВА,
Түбән Кама, Каенлы урта мәктәбе,
5 нче сыйныф.

КЕМ ГАЕПЛЕ?

Элеккеге заманнарда кешеләр янгынны Алланың үзләренә ачулануы дип уйлаганнар. Имеш, гонаһлары өчен ходай аларга җәза җибәргән! Янгынны сүндерәсе урынга алар догалар укыганнар, ялварганнар.

Чынлыкта, янгыннар кешеләрнең үз саксызлыгы аркасында килеп чыга бит!.. Минем белән килешәсезме?

Резидә МӨХӘММӘТГӘРӘЕВА,
Тукай районы,
7 нче сыйныф.

* * *

Минем әтием егерме ел буе янгын сүндерүче булып эшли. Мактаулы бүләкләре дә бик күп.

Үзенең эше хакында әтием аз сөйли. Ә менә балаларның шаярулары аркасында килеп чыккан янгыннар турында мин белеп торам. Күптән түгел генә шундый хәл булган. Әти-әнисе, ике кечкенә баласын өйдә калдырып, кунакка китәләр. Сабыйлар, кызык эзләп, шырпы белән уйнарга керешә. Өйдә ут чыга. Балалар икесе дә төтенгә буылып үлә!..

Сөйләп, аңлатып бетереп булмаслык кайгы бит!

Диана ҖӘЛӘЛИЕВА,
Казан, 14 нче мәктәп.





Ирина Шепелева
Яр Чаллы



Илсия Ибәтуллина
Буа районы





Тимур Тимершин
Яр Чаллы

Олеся Павлачева
Лениногорск

РӨСТӘМ МИНГАЛИМ

Өч Закир һәм аларның өч малае турында хикәят

Булса да була бит
шундый кешеләр?!
Әйе, була
шундый кешеләр:
«күкрәкләре
калкан-калкан,
мускуллары
шалкан-шалкан».
гаҗәп көчлеләр!
Безнең дә авылда,
нәкъ безнең урамда
бар шундый өч батыр:
«йодрыклары
чүлмәк-чүлмәк»,
чәчләре
кырып алынган,
башлары тап-такыр.
Әлбәттә, аларны
сез инде белмисез.
Сез безнең авылга
нигәдер килмисез.
Бар бездә өч Закир!
Килегез?
Күрерсез!

Аларга әбиләр:
— «Балакай!»— дип
тора.
Һәр малай аларга:
— «Абыкай!» — дип
тора,
елмаеп, кул биреп,
кунакка чакыра.
Бар бездә өч Закир,
өчәү тиң батырлар!
Һәркемгә билгеле —
янгынчы Закирлар!
Өч Закирның берсенә
бик рәхмәтле Гөлсинә.
Ул инде үсеп килә,
Гөлсинә инде белә.
Янгынчы Закир абый
уттан коткарган аны:
күреп янган зур өйне,
бәреп кергән ишекне.
Алып чыккан урамга
Гөлсинәле бишекне.

Өч Закирның икесе,
алары узган айны —
коткарганнар янудан
әби белән бабайны.

Узган елда өч Закир
чак янмаган үзләре:
коткарганнар янгыннан
сыерлар, үгезләрне,
сарыклар, бозауларны,
«Каравыл» дигән өйне,
ялгыш йокыга киткән
каравылчы кешене,
каравылчы янында
елап торган песине.

...Һәм,
озын сүзнең кыскасы,
озын сүзнең кыскасы
шул:
Закирларның һәрберсе дә,
барлык авыл кешесе дә,
олысы да, кечесе дә —
авылыбызда башка янгын
булмаганын телиләр.
Җир шарында башка янгын
чыкмаганын телиләр.
Өч Закирның өч малае,
чүт-чүт кенә мактанчыклар:
— Үскәч янгын сүндерүче
булабыз! —
дип йориләр.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ


Табышмак әйтәм — җавабын тап




Ялт-ялт итәр, ялмап йотар.



Ой түбәсендә аю бии.



Бүз күлмәк кигән, башы тактага тигән.



Ак ашый, кара төкерә.

Рәссам Ростәм ХӘБИБУЛЛИН

Халык әйтсә — хак әйтә



Рәссам Ростәм ХӘБИБУЛЛИН

Рөстәм МИНГАЛИМ

ДӨРЕСЕ АНЫҢ ШУЛАЙ...

Нәни хикәя

Әтисе кызын балалар бакчасыннан алган. Сөйләшә-сөйләшә өйләренә кайтып баралар:

— Кызым, бигрәк күп сорау бирәсең, һаман мине сөйләндерәсең, тәмам арыттың бит,— ди әтисе.— Менә хәзер мин сиңа сорау бирим әле. Син җавап бир. Рәхәтләнеп сөйлә.

— Нәрсә сөйлим? — ди кызчык.

— Бүген бакчада нинди матур уеннар уйнадыгыз? Шуны сөйлә,— ди әтисе кызына.

— Без бүген бакчада кулга-кул тотышып, түгәрәк ясап, сөйлән-бәйлән уйнадык,— ди кыз.

— «Сөйлән-бәйлән» түгел, «Әйлән-бәйлән» уены ул, кызым,— ди әтисе.

— Тәрбияче апа да «Әйлән-бәйлән» дип әйтә. Дөрес әйтми. Син дә ялгыш әйтәсең,— ди кыз.

— Менә сиңа?! Тәрбияче апаң да дөрес әйтми. Мин дә ялгыш әйтәм... Ничек инде алай? — ди әтисе.

— Шуны да белмисез. Үзегез зурлар. Ә без — кечкенәләр, сөйлән кебекләр. Шуңа күрә без «Сөйлән-бәйлән» уйнадык. Дөресе аның шулай,— ди кыз.

Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ

Марат ЗАКИР

ЯҢГЫРДАН СОҢ

...Күзләрен ачты
Нәни бөреләр.
Әй, шатландылар,
Әй, көлештеләр.

Тәмләп эчтеләр
Ширбәт-тамчыны.
Гөлләргә күчте
Алар шатлыгы.

ИРТӘ

Кузгалаклы болында
Тынгы белми кич-иртә,
Кем ул анда, кем икән
Елап ята бишектә?

Елавыннан туктаса
(Җитәр инде, һай, җитәр!),
Болын буйлап нык басып,
Тәпи-тәпи ул китәр.

...Уч төбендә Кузгалак
Чык тамчысын биетә:
Әле тәпи китәргә
Бик иртә, ди, бик иртә...

Каян килгән шаян җил —
Бишек бавын селкетә!
Болындашлар һәммәсе
Һаман көтә...
Ни көтә?

...Кемне димсез — Айдарны
Яланаяклы Иртә
Кулыннан тотып, әнә,
Болын буйлатып йөртә.



Бор
шаг

ЙОЛЫГ

Моннан мең ярым еллар элек барлыкка килгән Төрк каганатының (патшалыгының) җирләре Каспий диңгезеннән алып Кореяга кадәр җәелә. Бераздан ул шулкадәр көчәя, аның белән көчле дәүләтләр — Иран, Бизан, Кытай — санлашырга мәҗбүр була.

Ләкин каганатта биләр, аксөякләр бер-берсе белән тыныша алмыйлар, дау чыгаралар. Шуңа бу ил икегә бүленә, аның көнчыгыш өлеше Кытай кулы астына төшә.

Билгә каган (патша) белән энесе Күлтәгин үлгәч, аларның уллары тәхет өчен янә үзара дау башлыйлар. Ике баһадир хөрмәтенә зур кабер ташлары куела. Аларның туганы Йолыг тәгин шуларга үзенең

ынгы
ыйрлэр

ТӘГИН

шигырьләрен уеп яза. Төрк дәүләтенең таркалуына, жирләренең дошман кулына төшүенә халык белән бергә кайгыра шагыйрь:

Төрк халкы болай диде:
илле халык идем,
илем инде кайда?
Кем иле өчен казганырмын, диде.
Каганлы халык идем,
каганым кайда?
Нә каганга эшем-көчем бирермен,
диде.

Борынгы шагыйребез Йолыг тәгиннең бу сүзләре хәзер дә гыйбрәтле яңгырый. Бүген дә безгә бердәмлек житми бит. Бердәмлек булса ил-дәүләтебез дә көчәер, чын каганыбыз да сайланыр.

Ркаил Зәйдулла хикәяләвендә бирелә.

Кремль буйлап сәяхәт

Уен кагыйдәсе

Уенда ике яки берничә бала катнаша ала. Ян-якларына бердән алып алтыга кадәр нокта төшерелгән шакмакчыкны алмаш-тилмәш ташлаганнан соң, уйнаучыларның һәммәсе дә төймәләр ярдәмендә (фишки) күрсәтелгән юнәлеш буенча үзләренә тиешле йөреш ясый. Әгәр, мәсәлән, синең төймә кызыл түгәрәккә чыга икән, өстәмә йөреш ясарга кирәк. Әгәр төймә зәңгәр түгәрәктә туктаса, киләсе йөреш вакытында шул урында тик торсын. Әгәр төймә ук чыгып киткән түгәрәккә эләксә, төймә ук килеп төртелгән түгәрәккә күчерелә. Кем беренче булып Кремль буйлап сәяхәтне тәмамлый, шул җиңүче була.

Кремль манаралары:

1. Спас манарасы — XVI гасырда төзелә, XVIII гасырның беренче яртысында реконструкцияләнә. Манараның биеклеге — 46,6 метр.
2. Көньяк — Көнбатыш манара.
3. Көнбатыш (Исемсез) манара.
5. Тайницкая манарасы.
6. Воскресенская манарасы.
7. Консисторская манарасы.
8. Көньяк — Көнчыгыш манара.

Кремль манаралары, төзелү чорына карап, таш (XVI гасыр урталары), кирпеч-таш (XVI ахырлары) һәм кирпеч (XVIII—XIX) төрләренә бүленеп йөртеләләр.

Башка төр тарихи-архитектура ядкарьләре:

9. Благовещенск соборы — 1561—1562 елларда Псков осталары тарафыннан төзелә. XVIII гасырның беренче яртысында һәм XIX гасырда төзәтмәләр кертелә.

10. Сөембикә манарасы. Манара 4 һәм 8 кырлы бүлекләрдән һәм 6 кырлы түбә-сөңге белән төгәлләнгән 7 яруслы корылмадан гыйбарәт. Очында — ярымай. Биеклеге — 58 метр. Манара үзәк күчәрдән төньяк-көнчыгышка табан 1,7 метр чамасы авыша төшкән.

11. Элеккеге Сарай чиркәве. Төзелү вакыты мәгълүм түгел. Ул Нур Гали мәчете нигезендә торгызыла.

12. Элеккеге губернатор сарае. XIX гасырның 40 нчы елларында архитектор К. Тон тарафыннан византия стиленә охшатып төзелә. Хәзер биредә Татарстан Республикасы Президенты резиденциясе урнашкан.

13. Элеккеге Консистория — епархиаль архиерей каршындагы чиркәү идарәсе органы бинасы.

14. Элеккеге Архиерей йорты.

15. Элеккеге дәүләт учреждениеләре урнашкан бина. Биредә губернаның һәртөрле административ учреждениеләре урнашкан булган. Хәзер ул Татарстан Республикасының күп санлы министрлыклары һәм ведомстволары карамагында.

16. Элеккеге Юнкерлар (пехота) училищесы бинасы. 1866 елда сафка баса. Хәзер хәрби часть урнашкан.

17. Элеккеге артиллерия хуҗалыгы бинасы. XVIII—XIX гасырларда биредә Казан арсеналы һәм артиллерия хуҗалыгы урнашкан була; 1812—1815 елларда исә Россиядә иң эре тәп кою заводы эшләп килә.

18. Элеккеге гауптвахта бинасы. XIX гасыр урталарында, XVIII гасырда яшәп килгән цейхгауз — губерна канцеляриясе карамагында хәрби кирәк-яраклар складлары урынында барлыкка килә.

Вера НОВИКОВА.



8 (78) — 1996

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ

1990 елның март аеннан бирле чыга

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Җаваплы сәркатип
Илнур ДӘҮЛӘТША

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Фәрит МУЛЛАХМӘТ рәсемнәре

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

«Салават күпере» ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году. Выходит при участии АО «ПОИНТ — Вена — Казань».

Адрес редакции: 420012, г. Казань, ул. Комлева, 14. Редакция журнала «Салават күпере».

Производствога бирелде 25.07.96 ел. Басарга кул куелды 2.09.96 ел. Кәгазь форматы 84 × 108 1/16. Басма табак 1,5 (2,1). Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 10820 данә. Заказ Е-386. Бәясе килешү буенча.

АКЦИОНЕРНОЕ ОБЩЕСТВО
JOINT STOCK COMPANY



ВЕНА-КАЗАНЬ WIEN-KAZAN

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



КАЗЛАР, КАЗЛАР...

Касыйм ТӘХӘУ шигыре
Луиза ХӘЙРЕТДИНОВА кое











Балалар: Казлар, казлар, га-га-га,
Әйдә киттек елгага.
Чумып-чумып йөзәрбез,
Чиста булдык, диярбез.
Казлар: Кыйгак-кыйгак, га-га-га,
Без бармыйбыз елгага.
Без болай да ап-аклар,
Кызыл тәпи ак казлар.
Балалар: Казлар, казлар, га-га-га,
Кермәгез сез бакчага!
Елга буе чирәмлек —
Сезгә азык җитәрлек.
Казлар: Кыйгак-кыйгак, га-га-га,
Без бармыйбыз бакчага.
Балалар: Кыйгак-кыйгак, га-га-га,
Әйдә киттек елгага!